ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.07.2022 г. Заинск № 351

**«Торак урыны мәйданының хисап нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданы бирү нормасы турында» 2021 елның 12 июлендәге 456 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү хакында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 50, 58 статьялары нигезендә, Дәүләт торак программаларын тормышка ашыру йөзеннән, Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. «Торак урыны мәйданының хисап нормасы һәм социаль наем шартнамәсе буенча торак урыны мәйданы бирү нормасы турында» 2021 елның 12 июлендәге 456 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты карарына үзгәреш кертергә:

1.1. 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районында гражданнарны торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә алу максатларында, аларны торак урын гомуми мәйданы белән тәэмин итү дәрәҗәсен билгели торган торак урыны мәйданының хисап нормасын гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган торак урынның гомуми мәйданын 15 квадрат метрдан да артмаган күләмдә билгеләргә».

2. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының оештыру бүлегенә әлеге карарны Зәй муниципаль районының http://zainsk.tatarstan.ru рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында урнаштырырга.

3. Карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Э.Э.Галеев**

юрист
С.А.Филюшина
7 07 75